СОВЕТ ЦИПЬИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕПЬЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ
«29» июнь 2022 ел

КАРАР
№ 63

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегендә гавами тыңлауларын (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2021 елның 11 июнендәге 191-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп, нигезендә, «Гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау турында» 2022 елның 15 апрелендәге 02-08-01-2022 номерлы протест һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге Уставы нигезендә, Чепья авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышуларын) үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 6 статьясының 4 пунктындагы икенче абзацында " язма формада" сүзтезмәсеннән соң түбәндәге эчтәлектәге сүзтезмә өстәргә: " яисә җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны оештыручы адресына электрон документ формасында";

1.2. Нигезләмәнең 6 статьясындагы 5 пунктында " язма" сүзеннән соң "яисә электрон документ формасында" сүстезмәсен өстәргә;

1.3. Нигезләмәнең 7 статьясындагы 6 пунктында "язма» сүзеннән соң " яисә электрон документ формасында " сүзтезмәсен өстәргә;

1.4. Нигезләмәнең 8 статьясындагы 2 пунктында "язма формада" сүзтезмәсеннән соң түбәндәге эчтәлектәге сүзтезмә өстәргә: "яисә җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыжлауларны оештыручы адресына электрон документ формасында»;

1.5. Нигезләмәнең 5 нче кушымтасында «язма» сүзеннән соң "яисә электрон документ формасында" сүзтезмәсен өстәргә.

2.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.(baltasi.tatarstan.ru)

Чепья авыл җирлеге башлыгы А.Г.Нотфуллин